**СОВЕТ**
**Исенбаевского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Исәнбай авыл җирлеге**
**СОВЕТЫ**

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

20.06.2024 Исәнбай авылы № 47-1

“Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының “Исәнбай авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында” 31.01.2019 елның 48-1 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Исәнбай авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив-хокукый актларны Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Исәнбай авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. “Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының “Исәнбай авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында” 31.01.2019 елның 48-1 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Исәнбай авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1) 20 бүлекнең 11 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм муниципаль хезмәткәрләргә аны узу чорында граждан тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрне тикшерүне оештыру һәм уздыру;»;

2) 20 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 11_1 пунктын өстәргә:

"11_1) дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматка билгеләнгән форманы кертүне рәсмиләштерү;".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Исәнбай авыл җирлегенең мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында

(https://www.agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) .

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Совет рәисе урынбасары,
Авыл җирлеге башлыгы урынбасары Х.И.Ягъфаров